ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2021 п.г.т.Алексеевское № 89

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләр буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 160 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 18 декабрендәге 1148 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча һәм «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләр буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 160 номерлы карары белән расланган җирләрне аренда түләвен кичектереп тору шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Арендатор икътисадый эшчәнлекнең төп яисә өстәмә төрләре буенча билгеләнә, алар турында мәгълүмат юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында яисә индивидуаль эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә торышы буенча бирелә.»;

3 пунктта:

беренче абзацта «2020 елның 1 октябренә кадәр» сүзен «2021 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) кичектерү тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә бирелә;».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районының мөлкәти җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А. Гайнуллин**